КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Мишәбаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

29.11.2024 ел №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 28 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2024 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Мишәбаш торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче Мишәбаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Мишәбаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын ремонтлау (чокырлы), вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

2) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Мишәбаш торак пунктында янгын сүндерү гидрантлары өчен янгын рукавлары, колонкалар һәм стволлар сатып алу)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 208 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 108 кеше тавыш бирүдә катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 108 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче торак Мишәбаш пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.
«2025 нче елда Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Мишәбаш торак пунктында Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге составына керүче

Мишәбаш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,0 сум күләмендә үзара салым кертүгә" һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме? - дигән сорау буенча:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Мишәбаш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын ремонтлау (чокырлы), вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

2) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Мишәбаш торак пунктында янгын сүндерү гидрантлары өчен янгын рукавлары, колонкалар һәм стволлар сатып алу)карарын кабул ителгән дип танырга.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче
Явлаштау авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев